# Китапларга иман китерү

## الإيمان بالكتب

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM

- كيف نتعرف على الله ربنا؟

**Аллаһ безнең Раббыбыз икәнен без ничек белдек?**

- كيف نعبده كما أمرنا؟

**Ничек итеп без Ул әмер иткән төсле гыйбадәт кылыйк?**

- ما المنهج الذي يرضاه لنسير عليه؟

**Аллаһ бездән риза булсын өчен без нинди юлдан барыйк?**

كل هذا نعرفه من خلال الكتب السماوية.

**Боларның барысын да без күктән иңдерелгән китаплар аркылы танып алабыз.**

وهي الكتب والصحف التي حوت كلام الله تعالى.
الذي أوحاه إلى رسله عليهم الصلاة والسلام.

**Һәм алар Аллаһның сүзләрен үз эченә алган китаплар һәм язмалар. Шул сүзләрен Аллаһ илчеләренә иңдергән, аларга Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын.**

- والإيمان بها ركن من أركان الإيمان الستة.

**Китапларга ышану – алты иман нигезенең берсе.**

قال تعالى :

يا أيها الذين آمنوا آمِنُوا بالله ورسوله والكتاب الذي نزل على رسوله والكتاب الذي أنزل من قبل

**Аллаһ әйтте: «Әй иман китергән бәндәләр, Аллаһка, Аның илчесенә һәм Аның илчесенә иңдерелгән һәм аңа кадәр иңдерелгән китапларга иман китерегез».**

فنؤمن أنها كلها حق وصدق وأنها كلام الله تعالى فيها الهدى والنور والكفاية لمن أُنزِلَت عليهم

**Шулай итеп, без ул китапларның барысы да хак һәм дөрес булганына, һәм шулай ук алар Аллаһның сүзләре икәненә, бу китапларда хидәят, нур һәм кемнәргә җибәрелгән булса, шуларга җитәрлек икәненә ышанабыз.**

ونؤمن بما ذكر منها تفصيلا وهي القرآن والتوراة والإنجيل والزبور وصحف ابراهيم وموسى.

**Алардан аерым искә алынганнарына: Коръәнгә, Тәуратка, Иңҗилгә, Зәбурга, Ибраһим һәм Муса язмаларына ышанабыз.**

والقرآن الكريم ناسخ لجميع الكتب السابقة وحاكم عليها.

**Коръән – ул барлык аңа кадәр булган китапларны гамәлдән чыгаручы һәм алар өстеннән хакимлек итүче китап.**

قال تعالى :

وأنزلنا إليك الكتاب بالحق مصدقا لما بين يديه من الكتاب ومهيمنا عليه

**Аллаһ әйтте: «Без сиңа әүвәлге китапларның раслаучы, шаһит буларак, хаклык белән Китаб иңдердек».**

فلا يجوز العمل بشيء من أحكامها إلا ما صح منها واقره القرآن
فقد وقع فيها التبديل والتحريف.

**Әгәр әүвәлге китапларда килгән әхкәмнәр, Коръәндәге әхкәмнәргә туры килмәсә, аларга таянып гамәл кылу тыелган, чөнки ул китапларда үзгәрешләр, хата-бозыклар бар.**

وتكفل الله بحفظ القرآن كما قال الله تعالى: إنا نحن نزلنا الذكر وإنا له لحافظون

**Аллаһ Үз-Үзенә Коръәнне саклау җаваплылыгын алды. Аллаһ әйтте: «Хакыйкатьтә, Без искәртмә җибәрдек һәм Без аны сакларбыз».**

ومن ثمرات الايمان بالكتب:

**Китапларга иман китерүнең нәтиҗәләре:**

- شكر الله تعالى على عنايته بخلقه حيث أنزل لكل قوم كتابا يهديهم به ومعرفة حكمته في ذلك.

**Аллаһ Үз мәхлуклары турында кайгырту йөзеннән барлык халыкларга туры юлга өндәүче китап җибәргәне өчен шөкер кылу һәм шушы мәсьәләдә Аллаһның хикмәте барлыгын белү.**

ومن ثمرات الإيمان بالقرآن الكريم العناية به تلاوة وتعلما وعملا وتدبرا.

**Коръәнгә ышануның җимешләреннән: Коръәнне уку, аны үзләштерү, аның буенча гамәлләр кылу һәм мәгънәсен аңлап уйлану.**

فإنه النور المبين والصراط المستقيم وموعظة وذكرى وشفاء لما في الصدور. قال تعالى: كتاب أنزلناه إليك مبارك ليدبروا آياته وليتذكر أولوا الألباب

**Чынлыкта, ул ап-ачык нур, туры юл, үгет-нәсихәт, искә төшерүче һәм йөрәкләрдә булган нәрсәләргә шифа. Аллаһ әйтте: «Без сиңа, аятьләрен укып уйлансыннар өчен һәм гыйлем ияләре вәгазьләнсеннәр өчен күп файдалы вә бәрәкәтле китап иңдердек»**